| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**13.03.2019** | Зеленодольск<br>шәһ. | **КАРАР**<br>**№ 628** |
|---|---|---|

«Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына административ комиссия салган административ штрафлар түләү буенча бурычны түләтү мөмкин булмавын һәм аны юкка чыгару турында карар кабул итү Тәртибен раслау турында

РФ Бюджет кодексының 47.2нче маддәсенә ярашлы рәвештә, РФ Хөкүмәтенең 2016 елның 6 маендагы «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүнең ышанычсызлыгын тану турында карарлар кабул итү тәртибенә гомуми таләпләр турында» 393нче Карары белән, 2007 елның 2 октябрендәге «Башкарма производство турында» 229нчы ФЗ Федераль законы белән Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР ИТӘ:**

1.«Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына административ комиссия салган административ штрафлар түләү буенча бурычны түләтүнең ышанычсызлыгын тану һәм юкка чыгару турында карарлар кабул итү Тәртибен раслау (1нче Кушымта).

2.«Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына административ комиссия салган административ штрафлар түләү буенча бурычны түләтүнең ышанычсызлыгын тану һәм юкка чыгару турында карарлар һәм документлар кабул итү буенча Комиссия составын расларга (2нче Кушымта).

3. Әлеге карарны «Интернет» информацион-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнашгтырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольгә алуны үземдә калдырам.

Җитәкче Д.А.Сапожников

Зеленодольск
муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 13 мартындагы
628нче карарына 1нче кушымта

**«Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетында административ комиссия салган административ штрафлар түләү буенча бурычны түләтүнең ышанычсызлыгын тану һәм юкка чыгару турында карарлар кабул итү Тәртибе**

## I. ГОМУМИ ПОЛОЖЕНИЕЛӘР

1.1..«Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетында түләүләр буенча (түләү буенча төп бурыч, пенялар, штрафлар) бурычны түләтүнең ышанычсызлыгын тану һәм юкка чыгару турында карарлар кабул итүнең әлеге Тәртибе (алда – Тәртип). «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетында түләүләр буенча бурычны түләтүнең ышанычсызлыгын тану очракларын (алда – җирле бюджет), җирле бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүнең ышанычсызлыгын тану турында карарлар кабул итү өчен нигез булуны раслаган документлар исемлеген, активлар килү һәм чыгу буенча комиссиянең (алда – Комиссия) эш тәртибен билгели.

1.2. Әлеге Тәртип салымнар һәм җыемнар турында законнар, производствода бәхетсезлек очракларыннан һәм профессиональ авырулардан мәҗбүри социаль страхование турында Россия Федерациясе законнары, Евразия икътисади берлеге һәм таможня эше турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән түләүләргә кагылмый.

1.3. Әлеге Тәртиптә җирле бюджетка түләүләр буенча бурыч булып административ комиссия салган һәм җирле бюджетка күчерелергә тиешле һәм срогында түләнмәгән административ штраф тора. Җирле бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү ышанычсыз дип тану еллык хисапны төзер алдыннан инвентаризация уздыру нәтиҗәләре буенча алып барыла.

1.4. Җирле бюджетка бурычны түләтүне ышанычсыз дип тану инициаторы булып бюджетка түләүләрнең, алар буенча пенялар һәм штрафларның тулысынча һәм вакытында алып барылуын, исәпләүләрнең дөреслеген исәпкә һәм контрольгә алуны исәпләү буенча вәкаләтләр йөкләнгән җирле бюджет табышлары баш администраторы тора (алда –табышлар администраторы).

1.5.Табышлар администраторы бурычлар барлыгын ачыклый, әлеге Тәртипнең 10нчы пунктында каралган документлар җыю һәм тутыруны алып бара һәм җирле бюджетка түләүләр буенча бурыч түләтүне ышанычсыз дип тану турында мәсьәләне Комиссия каравына чыгара.

1.6. Табышлар администраторы җирле бюджетка түләүләр буенча бурыч түләтүне ышанычсыз дип тану турында карар кабул итү турында акт расланган көннән алып биш эш көне эчендә хисапчы исәп-хисабы турында Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына ярашлы баланс исәбеннән бурыч суммасын юкка чыгара. Бурычны юкка чыгару Россия Федерациясе Бюджет кодексының 47 маддәсенең 5нче пунктына ярашлы алып барыла.

1.7. Табышлар администраторы әлеге Тәртипнең 1нче кушымтасына ярашлы салым булмаган табыш төрләре буенча җирле бюджетка түләүләр буенча бурычны юкка чыгару реестрын алып бара.

## II. ҖИРЛЕ БЮДЖЕТКА ТҮЛӘҮЛӘР БУЕНЧА БУРЫЧНЫ ТҮЛӘТҮНЕҢ ЫШАНЫЧСЫЗЛЫГЫН ТАНУ ОЧРАКЛАРЫ

2.1. Бурычны түләтүнең ышанычсызлыгын тану һәм юкка чыгару түбәндәге очракларда алып барыла:

а) административ штраф түләүче физик затның үлеме яисә Россия Федерациясе гражданлык процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүе;

б) 2002 елның 26 октябрендәге «Түли алмау (банкротлык) турында» 127-ФЗ Федераль законга ярашлы бурычлының түләүләр буенча мөлкәте булмау сәбәпле җирле бюджетка бурычы түләнмәү өлешендә административ штраф түләүче шәхси эшмәкәрне банкрот дип танылуы;

в) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән кысаларда һәм тәртиптә оешманың һәм (яисә) күрсәтелгән оешманың оештыручысының (катнашучы) милке җитмәү сәбәпле капланмаган бурычы өлешендә салынган административ штрафның юкка чыгарылуы;

г) җирле бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү турында судка гариза бирүнең төшеп калган срогын торгызудан баш тарту турында суд билгеләмәсе чыгарылуга һәм шулай ук аны түләтү буенча билгеләнгән срогы чыгуга бәйле суд акты кабул ителүгә ярашлы җирле бюджет табышы администраторы җирле бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалтуы;

д) әгәр дә җирле бюджетка түләүләр буенча бурыч барлыкка килгән датадан алып биш елдан артык вакыт узса, 2007 елның 2 октябрендәге «Башкарма производство турында» 229-ФЗ Федераль законның 46нчы маддәсенең 1нче өлешендәге 3нче һәм 4нче пунктларда каралган нигезләүләр буенча суд пристав-башкаручының башкарма производствосының тәмамлануы һәм башкарма документ соратучыга кире кайтарылуы турында түбәндәге очракларда карар чыгара:

банкротлык турында эш буенча производство кузгату өчен түли алмау (банкротлык) турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән бурычлыга таләпләр күләменнән бурыч күләме артып китмәгәндә;

суд тарафыннан банкротлык турындагы эштә кулланылган процедуралар уздыруга суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акча булмауга бәйле банкротлык турында эш буенча производство туктатылган яисә банкротның җирле бюджетка түләүләрен түләүче дип тану турында гариза кире кайтарылганда.

2.2. Тәртипнең 8нче пунктында каралган очраклардан тыш, билгеләнгән срокта түләнмәгән административ җәзаларны өзү, туктату яисә шул срокны озайту өчен сәбәпләр булмаганда административ җәза билгеләү турында карарның үтәлү срогы чыгуда административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексы белән билгеләнгән срок чыкканда түләтүгә ышанычсыз дип таныла

## III. ҖИРЛЕ БЮДЖЕТКА ТҮЛӘҮЛӘР БУЕНЧА БУРЫЧ ТҮЛӘТҮНЕӊ ЫШНЫЧСЫЗЛЫГЫН ТАНУ ҺӘМ АНЫ ЮККА ЧЫГАРУ ТУРЫНДА КАРАРЛАР КАБУЛ ИТҮ ӨЧЕН НИГЕЗЛӘҮЛӘР БУЛУНЫ РАСЛАГАН ДОКУМЕНТЛАР ИСЕМЛЕГЕ

3.1. җирле бюджетта түләүләр буенча бурыч түләтүне ышанычсыз дип тану турында карар кабул итү өчен сәбәпләр күрсәтелгән документлар булып тора:

а) инвентаризацияләү турында акт (2015 елның 30 мартында «Дәүләт власте органнары ( дәүләт органнары),җирле бюджет органнары, бюджеттан тыш дәүләт фонды идарә органнары, дәүләт (муниципаль) учреждениеләре кулланган хисапчы исәбе регистрларын һәм башлангыч исәп документлары формаларын һәм аларны куллану буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» Россия Минфины 52н Боерыгы белән расланган 0504835 формасы);

б) акча килүләр буенча исәпләүләрне инвентаризацияләү исемлеге (2015 елның 30 мартында Россия Минфинының 52н Боерыгы белән расланган ф. 0504091);

в) әлеге Тәртипнең 2нче кушымтасына ярашлы форма буенча җирле бюджетка түләүләр буенча бурычның исәпләнгән суммасы турында табышлар администраторы хисабыннан күчермә;

г) җирле бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү буенча кабул ителгән чаралар турында табышлар администраторының белешмәсе;

д) җирле бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүне ышанычсыз дип тану очракларын раслаган документлар:

җирле бюджетка түләүче физик затның үлеме турында ачыклаган яисә аның үлгәнен игълан итү фактын раслаган документ;

җирле бюджетка түләүләр алып барган шәхси эшмәкәр банкрот дип танылу сәбәпле эшчәнлеген туктату турында шәхси эшмәкәрләр Бердәм дәүләт реестрыннан, җирле бюджетка түләүләр алып барган оешма юкка чыгуга бәйле эшчәнлеген туктату турында юридик затлар Бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр керткән документ;

җирле бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү турында судка төшеп калган гариза бирү срогын торгызудан баш тарту турында суд билгеләмәсенә, аны түләтүнең билгеләнгән срогы чыгуга (иск срогы чыгу) бәйле табыш администраторы җирле бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалтуына ярашлы суд акты;

2007 елның 2 октябрендәге «Башкарма производство турында» 229-ФЗ Федераль законның 46нчы маддәсенең 1нче өлешендәге 3нче һәм 4нче пунктларында каралган нигезләүләр буенча түләтүчегә башкарма документны кире кайтарганда башкарма производствоның тәмамлануы турында суд пристав-башкаручының карары.

## IV.ҖИРЛЕ БЮДЖЕТКА ТҮЛӘҮЛӘРНЕҢ ЫШАНЫЧСЫЗЛЫГЫН ТАНУ ҺӘМ АНЫ ЮККА ЧЫГАРУ БУЕНЧА БУРЫЧНЫ ТҮЛӘТҮНЕҢ ЫШАНЫЧСЫЗЛЫГЫН ТАНУ ТУРЫНДА КАРАРЛАР ӘЗЕРЛӘҮ МАКСАТЫННАН АКТИВЛАРНЫҢ КИЛҮЕ ҺӘМ КИТҮЕ ҺӘМ АНЫ ЭШЛӘТҮ ТӘРТИБЕ БУЕНЧА КОМИССИЯ ТУРЫНДА ПОЛОЖЕНИЕ

4.1. Комиссия составы даими нигездә табышлар администраторы тарафыннан раслана.

4.2. Комиссия рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм Комиссия әгъзаларыннан тора. Комиссия эшчәнлегенә рәис җитәкчелек итә, ул булмаганда - рәис урынбасары.

4.3. Комиссия утырышлары уздыру кирәге чыкканда уздырыла.

4.4. Комиссия утырышы, әгәр дә анда гомуми әгъзаларының өчтән ике өлешеннән кимрәге катнашса, дөрес дип санала. Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән Комиссия әгъзаларының иң күп гади тавыш җыю юлы белән беркетмә формасында кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта Комиссия рәисе хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия була.

4.5. Комиссия утырышы беркетмәсенә рәислек итүче һәм утырышта катнашучы комиссия әзгъзаларының барысы да имзасын куя.

4.6. Комиссия 10 эш көне эчендә Тәртипнең 10нчы пунктына ярашлы табышлар администраторы биргән документлар исемлеген карый һәм җирле бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүнең ышанычсызлыгын тану һәм аны юкка чыгару турында карар проектын әзерли. Җирле бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүнең ышанычсызлыгын тану турында карар әзерли .

4.7. Җирле бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүнең ышанычсызлыгын тану турында карарга түбәндәге мәгълүматлар кертелеп акт төзелә (3нче кушымта):

а) оешманың тулы исеме (физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме);

б) салым түләүченең идентификацияләү номеры, төп дәүләт теркәлү номеры, оешманың салым түләүчесен исәпкә кую коды(салым түләүче физик затны

идентификацияләү номеры);
в) бурыч барлыкка килгән штраф турында;
г) җирле бюджетка түләүләр буенча бурыч исәпкә алынган Россия Федерациясе бюджетлары табышлары классификациясе коды, аның исеме;
д) җирле бюджетка түләүләр буенча бурыч суммасы;
е) җирле бюджетка административ ратив штраф түләү буенча бурычны түләтүнең ышанычсызлыгын тану турында карар кабул ителү датасы;
ж) комиссия әгъзалары имзалары.
4.8. Комиссиянең җирле бюджетка административ штраф түләү буенча бурыч түләтүнең ышанычсызлыгын тану һәм аны юкка чыгару турында төзегән акты табышлар админитстраторы тарафыннан раслана.

«Зеленодольск муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге бюджетына
түләүләр буенча бурычны түләтүнең
ышанычсызлыгын тану һәм
юкка чыгару турында карарлар
кабул итү Тәртибенә
1нче кушымта

Салым булмаган табыш төрләре буенча «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына
түләүләр буенча юкка чыгарылган бурыч
РЕЕСТРЫ

_______ ел өчен

_________________________________________________
(табышлар администраторы)

(сум)

| № п/п | Ышанычсыз бурычны тануга нигезләүләр | Оешма исеме (ИНН/КПП), физик затның Ф.И.О. (ИНН булганда) | Түләү төре | Түләү буенча бурычның барлыкка килү срогы | Юкка чыгарылган бурыч суммасы барлыгы | Шул исәптән: | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Төп бурыч | Пени | Штрафлар |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| Барлыгы | | | | | | | | |

Җитәкче

М.П. _____________ _______________________
(имза) (Ф.И.О.)

«Зеленодольск муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге бюджетына
түләүләр буенча бурычны түләтүнең
ышанычсызлыгын тану һәм списать
итү турында карарлар
кабул итү Тәртибенә
2нче кушымта

«Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр түләү буенча бурычның исәпләнгән суммалары турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты хисабыннан

КҮЧЕРМӘ

________________________________________

(оешманың исеме (ИНН/КПП),
Физик затның Ф.И.О. (ИНН булганда)
________________елда торышы

(сум.)

| № п/п | Түләү төре | Түләү буенча бурыч барлыкка килү срогы | Түләү буенча барлыгы бурыч | Шул исәптән: | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Төп бурыч | Пени | Штрафлар |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| БАРЛЫГЫ | | | | | | |

Җитәкче

М.П. _____________ _______________________
(имза) (Ф.И.О.)

«Зеленодольск муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге бюджетына
түләүләр буенча бурычны түләтүнең
ышанычсызлыгын тану һәм списать
итү турында карарлар
кабул итү Тәртибенә
3нче кушымта

Бюджетка түләүләр буенча бурчының ышанычсызлыгын тану
һәм аны юкка чыгару турында
АКТ

«____» ________________ 20__елдан № ____

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________
(оешманың тулы исеме, физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

_______________________________________________________________________________
(ИНН, ОГРН, КПП)

Бурыч барлыкка килгән түләү турында белешмә

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________
(КДБ һәм аның исеме)

Бурыч суммасы ___________ сум ____ тиен

Нигезендә

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________
(реквизитлар белән төгәл документлар күрсәтелә)

Комиссия рәисе ______________________/______________/_________________
(вазифа) (имза) (Ф.И.О.)

Комиссия әгъзалары: _____________________________/______________/_______________
(вазифа) (имза) (Ф.И.О.)

_______________________________________________/______________/____________
(вазифа) (имза) (Ф.И.О.)

Зеленодольск
муниципаль районы
Башкарма комитетының
13.03.2019 № 628
карарына 2нче кушымта

**«Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына административ комиссия салган административ штрафлар түләү буенча бурыч түләтүнең ышанычсызлыгын тану һәм юкка чыгару турында документлар карау һәм карар кабул итү буенча Комиссия составы**

| | |
|---|---|
| **Комиссия рәисе:** | |
| Старостин Александр Владимирович | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары |
| **Рәис урынбасары:** | |
| Мөхәммәтханов Тимур Фәрит улы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының баш хисапчысы |
| **Сәркатип:** | |
| Хохлова Ирина Николаевна | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты административ комиссиясенең баш белгече |
| **Комиссия әгъзалары:** | |
| Угненко Лилия Ивановна | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты хисапчысы |
| Абросимова Ольга Михайловна | «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ – техник инспекциясе идарәсе» МКУ җитәкчесе |